
# Нуриева Шәмсекамал Җәләлетдин кызы



Нуриева Шәмсекамал Җәләлетдин кызы 1931 нче елның 8 нче февралендә Мамадыш районы Keче Сон авылында туган. Әтисе –Кадыйров Җәләл Назир улы, 1917 елгы сугышта катнаша, әсирлеккә төшә, мең газаплар белән аннан качып туган авылына кайтып егыла.

Шәмсекамал апа башлангыч мәктәпне Кече Сон авылында тәмамлый. Әтисенең һөнәре ( ул итек баскан) гаиләне ачлык елларда саклап калган.

Сугыш башланган чорларны Шәмсекамал апа болай дип искә ала: "Без өченче сыйныфны тэмамлаганда Бөек Ватан сугышы башланды.Әниләребез көне-төне колхоз эшенә йөри. Безгә, ун-унике яшьлек балаларга, хуҗалыктагы бөтен эшне эшләргә туры килә. Мин үзем , мәсәлән, гаиләдә өлкән бала, миннән кечерәкләре тагын өчәү иде. Шулай итеп, балалыктан бик иртә чыктык без. Мәктәпкә дә, өйгә дә ягарга узебез әзерләдек. Бәләкәй арбаларга , чаналарга төяп, утынны урманнан үзебез алып кайта идек.

Эштән курыкмый идек без. Без бер көн дә , бер сәгать тә эштән калмадык.Атлар барысы да фронтта, ат урынына сыерлар, үгезләр җигәләр иде. Безгә сыер җигеп шактый җирне сукаларга, тырмаларга туры килде. Моннан тыш, басудан чүп үләннәр утарга, урак урырга, ашлык сугарга һәм тагын бик күп эшләргә йөрдек. Паром белән Кама елгасы аша печән ташыдык.Урман кистек."

1954 нче елда Шәмсекамал апа Югары Сон егете Нурыев Гаалиәхмәткә кияүгә чыга. Алар тормыш иптәше белән 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Шәмсекамал апа фермада сыер сава, Галиәхмәт абый маллар карый. Галиәхмәт абый инде вафат. Шәмсекамал апа малае Рәүф, килене Алмазия тәрбиясендә яши. "Сугыш яңадан кабатланмасын, табыннарыбыз икмәкле булсын", ди ул.